ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.12.2020 Казан ш. № 412-72/тэ-2020

«Зеленодольск җылылык челтәрләре» ачык акционерлык җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга, җылы белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2018 № 5-76/тэ карары белән билгеләнгән дәвамлы тарифларга 2021 ел өчен төзәтмәләр кертү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, 2021-2023 елларга җайга салынулы оешманың планлаштырылган кирәкле тулай керемен тәгаенләштереп, 2021-2023 елларга җылылык энергиясенә (егәрлегенә) озак сроклы тарифларны төзәтү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Зеленодольск җылылык челтәрләре предприятиесе» ачык акционерлык җәмгыятеннән кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2019-2023 елларга тарифлар билгеләү турында» 11.12.2018 № 5-76/тэ карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 27.11.2019 № 5-55/тэ карары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «Зеленодольск җылылык челтәрләре предприятиесе» ачык акционерлык җәмгыяте» сүзләрен «Зеленодольск җылылык челтәрләре предприятиесе» акционерлык җәмгыяте» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «Зеленодольск җылылык челтәрләре предприятиесе» ачык акционерлык җәмгыяте» сүзләрен «Зеленодольск җылылык челтәрләре предприятиесе» акционерлык җәмгыяте» сүзләренә алмаштырырга;

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

2 нче кушымтаның 1 пунктында «Зеленодольск җылылык челтәрләре предприятиесе» ачык акционерлык җәмгыяте» сүзләрен «Зеленодольск җылылык челтәрләре предприятиесе» акционерлык җәмгыяте» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2018 № 5-76/тэ карарына 1 нче кушымта (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2020 № 412-72/тэ-2020 карары редакциясендә)

## «Зеленодольск җылылык челтәрләре предприятиесе» акционерлык җәмгыятеннән кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2019-2023 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, җайга салынулы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | су | Басым астында сайланма пар | | | | Әче һәм редукцияләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 $кг/см^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 $кг/см^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 $кг/см^2$ кадәр | 13,0 $кг/см^2$ югары | |
| | Зеленодольск муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | «Зеленодольск җылылык челтәрләре предприятиесе» акционерлык җәмгыяте | | | | | | | |
| 1.1 | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 1568,30 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 1605,94 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 1605,94 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 1653,71 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 1653,71 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 1719,84 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 1673,41 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 1715,82 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 1715,82 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 1764,63 | - | - | - | - | - |
| 1.2 | Халык (тарифлар НДС исәпкә алып күрсәтелде)* | | | | | | | |
| | Бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 1881,96 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 1927,13 | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 1927,13 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 1984,45 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 1984,45 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 2063,81 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 2008,09 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 2058,98 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 2058,98 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 2117,56 | - | - | - | - | - |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын тормышка ашыру максатларында аерып чыгарыла

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге